КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 март г.Казань № 232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары номенклатурасына һәм күләменә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 5 май, 296 нчы; 2016 ел, 24 май, 341 нче; 2017 ел, 20 июнь, 398 нче; 2021 ел, 22 июль, 640 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 825 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 1 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары номенклатурасына һәм күләменә үзгәрешләрне кертергә:

«Гадәттән тыш хәлдә зыян күргән халыкны тормыш эшчәнлеге белән тәэмин итүне оештыру» бүлегендә:

1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктның 4 графасында «8» санын «7» санына алмаштырырга;

«Гадәттән тыш хәл зонасында коткаручылар группировкасын җиһазландыру» бүлегенең 29, 34 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин